РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

29 июнь 2026 ел Буа шәһәре № 2-14

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 4-54 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмә биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтүләр җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2017 елның 19 июлендәге «Муниципаль вазыйфаны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 56-ТРЗ номерлы, 2017 елның 19 июлендәге «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 4-54 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең

сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмә биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтүләр җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында» карарына (19.05.2026 № 4-12 ред.) түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 4-54 номерлы карарына кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 4 өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, ТР Буа муниципаль районы Советы әгъзасын, вәкаләтләре чоры туктатылганчы, ТР Буа муниципаль районы Советында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итеп, ТР Буа муниципаль районы советындагы вазыйфасыннан азат итү;

3) вәкаләтләре чоры туктатылганчы вәкаләтләрне даими нигездә башкару хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советында аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләрне үз вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә башкаруны тыю.

1.2. Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 4-54 номерлы карарына кушымтаның 3 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып Татарстан Республикасы Рәисенең муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясындагы 3 өлешендә каралган җаваплылык чараларын куллану турында гаризасы тора.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru). рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов